| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18. 12. 2025 г.Мензелинск № 435

Аеруча кыйммәтле күчмә милеккә караган сәхнә милкен тапшыру, арендага яки бушка файдалануга бирү өчен, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы мәдәният оешмаларының милек хуҗасы һәм учредитель функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган белән килештерү Тәртибен раслау турында

2006 елның 26 июлендә кабул ителгән № 135-ФЗ «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законының $17^1$ статьясының $3^6$ өлешенә, дәүләт яки муниципаль мәдәният оешмаларының оператив идарә хокукы буенча ныгытылган спектакль (тамаша) сәхнә бизәлешенә яки стационар сәхнә җиһазларына караган дәүләт яки муниципаль милеккә карата конкурслар яки аукционнар үткәрмичә аренда килешүләре, бушка файдалану килешүләре төзү Кагыйдәләренең 8 пунктына, 2021 елның 24 сентябрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган № 1610 карарына ярашлы, театр-тамаша, мәдәни-агарту яки тамаша-күңел ачу чараларында куллану өчен, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1. Аеруча кыйммәтле күчмә милеккә караган сәхнә милкен тапшыру, арендага яки бушка файдалануга бирү өчен, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы мәдәният оешмаларының милек хуҗасы һәм учредитель функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган белән килештерү Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Минзәлә районы муниципаль берәмлеге сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга.
3. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ рәисе Р. С. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче М. Р. Кәримов

Расланган
Татарстан Республикасы Минзәлә
муниципаль районының Башкарма
комитеты карары белән
18 12 2025 ел № 435

Аеруча кыйммәтле күчмә милеккә караган сәхнә милкен тапшыру, арендага яки бушка файдалануга бирү өчен, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы мәдәният оешмаларының милек хуҗасы һәм учредитель функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган белән килештерү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәдәният оешмаларының (алга таба – мәдәният оешмалары) конкурслар яки аукционнар үткәрмичә, спектакль (тамаша) сәхнә бизәлешенә яки стационар сәхнә җиһазларына караган һәм мәдәният оешмаларына оператив идарә хокукы белән беркетелгән аеруча кыйммәтле күчмә милекне (алга таба - аеруча кыйммәтле күчмә милек) арендага, бушка файдалануга тапшыру өчен, әлеге милекне театр-тамаша, мәдәни-агарту яки күңел ачу чараларында куллану максатында милек хуҗасы һәм учредитель функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган белән килештерү процедурасын билгели.

2. Мәдәният оешмалары тарафыннан аеруча кыйммәтле күчмә милеккә карата аренда килешүләрен түләүсез файдалану килешүләрен төзү, 2006 елның 26 июлендәге № 135-ФЗ «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законының $17^1$ статьясының $3^6$ өлешенә ярашлы, конкурслар яки аукционнар үткәрмичә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 24 сентябрендәге № 1610 «Дәүләт яки муниципаль милеккә карата аренда килешүләре, түләүсез файдалану килешүләре, спектакльнең (тамашаның) сәхнә бизәлешенә яки стационар сәхнә җиһазларына караган һәм дәүләт яки муниципаль мәдәният оешмаларының оператив идарә хокукында ныгытылган милекне театр-тамаша, мәдәни-агарту яки тамаша-күңел ачу чараларында куллану өчен, мәдәниятнең дәүләт һәм муниципаль оешмаларының оператив идарә итү хокукында, конкурслар яки аукционнар үткәрмичә төзү Кагыйдәләрен һәм әлеге милек төрләренең исемлеген раслау турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә, шартларда һәм милек төрләре исемлегенә ярашлы башкарыла.

3. Мәдәният оешмасы, юридик зат яки шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән физик зат (алга таба – хуҗалык итүче субъект) тарафыннан аеруча кыйммәтле күчмә милеккә карата килешү төзү турында гариза кергән көннән башлап 5 эш көне эчендә, хуҗалык итүче субъектка аеруча кыйммәтле күчмә милекне арендага яки бушка файдалануга тапшыруны килештерү турында мөрәҗәгатьне (алга таба - мөрәҗәгать) язмача рәвештә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы" МКУга җибәрергә тиеш.

4. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) хуҗалык субъектының исеме, урнашкан урыны турында мәгълүмат, почта адресы, контакт телефоны номеры;

2) арендага, бушка файдалануга тапшырырга тәкъдим ителгән аеруча кыйммәтле күчмә милек турында мәгълүмат (исеме, инвентаризация номеры (булган очракта), баланс бәясе, техник характеристикалар һәм аеруча кыйммәтле күчмә милекне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирүче башка мәгълүматлар);

3) аренда килешүен, бушка файдалану килешүен төзү тәкъдим ителгән вакыт, аренда түләве күләме;

4) хуҗалык итүче субъект аеруча кыйммәтле күчмә милекне кулланырга планлаштырган театр-тамаша, мәдәни-агарту яки тамаша-күңел ачу чаралары турында мәгълүматлар.

5. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) аеруча кыйммәтле күчмә милеккә карата килешү төзү ниятен белдергән хуҗалык субъектының гариза күчермәсе;

2) хуҗалык субъекты физик зат булса, физик затның шәхесен раслаучы документның күчермәсе;

3) шәхесне раслаучы документның күчермәсе һәм гариза җибәрү датасына кадәр бер ай эчендә алынган шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – шәхси эшмәкәрләр өчен;

4) гариза җибәрү датасына кадәр бер ай эчендә алынган юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – юридик затлар өчен;

5) аеруча кыйммәтле күчмә милекне арендага бирү яки бушка файдалану килешүе проекты;

6) аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турында Россия Федерациясе бәяләү эшчәнлеге законнары нигезендә әзерләнгән хисап (тапшыру датасына 6 айдан артмаган вакыт белән);

7) хуҗалык субъектында мәдәният оешмасы белән элек төзелгән килешүләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләр булу (булмау) турында белешмә.

6. Мәдәният оешмасына ике һәм аннан күбрәк хуҗалык субъектыннан бер үк аеруча кыйммәтле күчмә милеккә карата гаризалар кергән очракта, мөрәҗәгатьләр гаризаларның килү датасыннан чыгып чират тәртибендә җибәрелә.

7. Мөрәҗәгатьне һәм аңа кушылган документларны карау нәтиҗәләре буенча аны теркәү көненнән 12 көн эчендә түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) аеруча кыйммәтле күчмә милекне арендага яки бушка файдалануга тапшыруны килештерү;

2) аеруча кыйммәтле күчмә милекне арендага яки бушлай файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту.

8. Аеруча кыйммәтле күчмә милекне арендага яки бушлай файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматларда һәм документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу;

2) хуҗалык итүче субъектның аеруча кыйммәтле күчмә милекне кулланырга планлаштырган чараларның театр-тамаша, мәдәни-агарту яки тамаша-күңел ачу чараларына туры килмәве;

3) хуҗалык итүче субъектның мәдәният оешмасы белән элек төзелгән килешүләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булу.

9. Кабул ителгән карар милек хуҗасы тарафыннан ТР Минзәлә муниципаль районының "Җир һәм милек мөнәсәбәтләре" МКУ боерыгы рәвешендә һәм учредитель тарафыннан Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты рәвешендә рәсмиләштерелә һәм мәдәният оешмасына кабул ителгән көннән 3 эш көне эчендә җибәрелә.

10. Аеруча кыйммәтле күчмә милекне арендага, бушлай файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә мөрәҗәгать һәм аңа кушылган документлар мәдәният оешмасына әлеге карар кабул ителгән көннән 7 көн эчендә кире кайтарыла.

11. Аеруча кыйммәтле күчемле милекне арендага, бушка файдалануга тапшыру турында кабул ителгән карар конкурслар яки аукционнар үткәрмичә, мәдәният оешмасы тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле милеккә карата аренда килешүе, бушка файдалану килешүе төзү өчен нигез булып тора.